КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 19 сентябрь г.Казань № 1016

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 13 март, 179 нчы; 2019 ел, 18 сентябрь, 846 нчы; 2020 ел, 28 февраль, 153 нче; 2020 ел, 25 август, 734 нче; 2020 ел, 22 декабрь, 1172 нче; 2021 ел, 26 июль, 649 нчы; 2021 ел, 7 декабрь, 1182 нче; 2022 ел, 28 февраль, 180 нчы; 2022 ел, 13 май, 439 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты турындагы нигезләмәгә, 3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле $3.3.21^1$ пунктча өстәп, үзгәреш кертергә:

«$3.3.21^1$. Мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларының гамәле кагылмый торган җир кишәрлекләрен файдалануны билгели, мондый җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төренә үзгәреш кертү турында карар кабул итә;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин